ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы муниципаль районының**
**Красновидово авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты**
Кама Тамагы районы,
Красновидово авылы
тел. 884377 2-04-13

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**Исполнительный комитет Красновидовского сельского поселения**
Камско-Устьинский район,
с. Красновидово
тел. 884377 2-04-13

КАРАР

27 сентябрь 2019 г. № 11

2018 елның 18 декабрендәге 13 номерлы “Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Башкарма комитетының Карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2019 елның 26 июлендәге 227-ФЗ номерлы ““Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы “Федераль мәгълүмат адреслы системасы турында “гы һәм “Федераль законга үзгәрешләр кертү турында”гы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР КЫЛА**:
1. 2018 елның 18 декабрендәге “Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Башкарма комитетының 13 номерлы Карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең

административ регламентына (алга таба - регламент) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:
1.5 пунктта:
өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"адрес - Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплары нигезендә структуралаштырылган һәм үз эченә шул исәптән урам-юл челтәре элементының һәм (яки) планлаштыру структурасы элементының атамасы (кирәк булганда), шулай ук адресация объектының санлы һәм (яки) хәреф-цифрлы билгеләнешен ала торган адресация объектының урнашу урыны тасвирламасы.;";
бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"адресация объекты - капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән адресация объектлары исемлеге белән каралган башка объект;".
2. Әлеге Карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:
ТР, Кама Тамагы районы, Красновидово авылы, Совет урамы, 4 йорт;
ТР, Кама Тамагы районы, Бортас авылы, Үзәк урамы, 3 йорт;
ТР, Кама Тамагы районы, Антоновка авылы, Колхоз урамы, 9а йорты,
шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтының "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Җитәкче** **В. П. Оленин**